КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 март г.Казань № 156

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль проектлар конкурсларын үткәрү турында» 2005 ел, 7 апрель, 167 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль проектлар конкурсларын үткәрү турында» 2005 ел, 7 апрель, 167 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 7 февраль, 72 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 837 нче; 2016 ел, 15 апрель, 226 нчы; 2016 ел, 21 декабрь, 856 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны, «республика» сүзен төшереп калдырып, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында социаль проектлар конкурслары турындагы нигезләмәне расларга.»

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Социаль проектларның республика конкурслары турындагы нигезләмәдә:

нигезләмәнең исемен, «республика» сүзен төшереп калдырып, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында социаль проектлар конкурслары турында нигезләмә»;

1.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасында социаль проектлар конкурслары турындагы

нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасында социаль проектлар конкурсларын (алга таба – Конкурс) оештыруга һәм үткәрүгә, иҗтимагый файдалы дип танылган һәм конкурс комиссиясе тарафыннан финанслауга тәкъдим ителгән социаль проектларны (программаларны, чараларны) гамәлгә ашыруны өлешчә максатчан финанслауга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.»;

II бүлектә:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Заявка – оешманың Конкурста катнашырга ниятләү турында язма мөрәҗәгатен үз эченә алган һәм вәкаләтле орган билгеләгән форма буенча конкурс комиссиясенә карау өчен җибәрелә торган документ. Заявка шулай ук электрон документ рәвешендә «Грантлар конкурсы» автомат мәгълүмат системасы аша бирелергә мөмкин. Электрон документ рәвешендә бирелә торган заявка оешма җитәкчесенең гади электрон имзасы белән таныкланырга тиеш. Бер оешма бары бер заявка гына бирергә мөмкин, аның составында Конкурста катнашу өчен бары бер социаль проект кына тапшырыла.»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чыгымнар сметасы (проект бюджеты) – заявкада бәян ителгән йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне финанслау өчен кулланыла торган һәм Вәкаләтле орган һәм Конкурста җиңүчеләр арасында төзелә торган социаль проектны (программаны, чараны) өлешчә максатчан финанслау турындагы шартнамә (алга таба – шартнамә) белән алга таба расланган акча керүнең һәм тотуның документлаштырылган бухгалтерлык планы.»;

унөченче абзацта «(Конкурс гранты)» сүзләрен төшереп калдырырга;

IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Шулай ук заявкалар бирү срогын башлау планлаштырылган айга кадәр килгән айның беренче көненә түбәндәге коммерциягә карамаган оешмалар Конкурста катнашучы оешмалар була алмый:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булган;

субсидияләрне, грантларны, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән Татарстан Республикасының башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында акча йөкләмләре буенча вакытында түләнмәгән башка бурычлары булган;

үзгәртеп оештыру (Конкурста катнашучы оешма булып торучы юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булган, банкротлык процедурасы билгеләнгән һәм эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылган;

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория торган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50

процентган артып киткән Россия юридик затлары булган;

бу Нигезләмәнең преамбуласында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә субсидия бирү каралган елда Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булган.»;

5.2 пунктның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

5.6 пунктның өченче абзацында «проектларны (программаларны, чараларны) өлешчә максатчан финанслау турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.7 пунктта:

алтынчы абзацта «катнашучыларның гаризаларын» сүзләрен «заявкалар» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацта «гаризаларны» сүзен «заявкаларны» сүзенә алмаштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка формасы;»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башка мәгълүматлар, шул исәптән бу Нигезләмәнең IV бүлеге нигезендә Конкурста катнашучы оешмаларга карата таләпләр һәм Конкурста катнашучы оешмалар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге.»;

6.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.8. Конкурс комиссиясе:

заявкаларны кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыра, шулай ук заявкаларны вакытында җибәргән оешмаларга аларны Конкурста катнашучылар дип тану яки танымау турында хәбәр итә;

заявкаларга экспертиза үткәрүне оештыра. Эксперт бәяләве конкурс комиссиясе тарафыннан экспертлар буларак җәлеп ителгән кимендә өч белгеч катнашында 10 баллы система буенча гамәлгә ашырыла;

Конкурска йомгаклар ясый, Конкурста җиңүчеләр исемлеген раслый;

Конкурс йомгаклары турындагы мәгълүматны Конкурста җиңүчеләр исемлеге расланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында бастырып чыгаруны тәэмин итә.»;

6.9 пунктның икенче абзацында «гаризада» сүзен «заявкада» сүзенә алмаштырырга;

6.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.10. Конкурс йомгаклары турындагы мәгълүматта, оешмаларның (Конкурста җиңүчеләрнең), социаль проектларның (программаларның, чараларның) тулы исеме һәм өлешчә максатчан финанслау суммасы күрсәтелеп, Конкурс номинацияләре буенча җиңүчеләр турында мәгълүматлар булырга тиеш.»;

7.5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Конкурста җиңүчеләргә акча бирү конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурста җиңүчеләр исемлеге расланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә төзелә торган шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацта «хисап бирү тәртибе һәм формасы» сүзләреннән соң «, шул исәптән әлеге хисапны «Грантлар конкурсы» автомат мәгълүмат системасы аша

бирү тәртибе» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вәкаләтле орган тарафыннан акча күчерү Конкурста катнашучылар тарафыннан шартнамәдә күрсәтелгән максатлар өчен субсидияне планлаштырып тотуны раслый торган документлар Вәкаләтле органга тапшырылган көннән соң килгән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Конкурста җиңүчеләрнең исәп-хисап счетына шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

VIII бүлек үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин